Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР №XXXII-9**

Балык Бистәсе штп. 24 июль 2018 ел

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районСоветының 2017 елның 21 ноябрендәге XXIII-3 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә гомуми файдаланудагы автомобиль транспорты тарафыннан гамәлгә ашырыла торган пассажирлар ташуны оештыру Тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” гы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 маддәсенә, 2015 елның 13 июлендәге “Россия Федерациясендә автомобиль транспорты һәм шәһәр җир өсте электр транспорты белән даими рәвештә пассажирлар һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында”гы 220-ФЗ номерлы Федераль законга, Татарстан Республикасының 2015 елның 26 декабрендәге “”Россия Федерациясендә автомобиль транспорты һәм шәһәр җир өсте электр транспорты белән даими рәвештә пассажирлар һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында”гы Федераль законны реализацияләү хакында”гы 107-ЗРТ номерлы Законына, 2018 елның 11 апрелендәге”” Россия Федерациясендә автомобиль транспорты һәм шәһәр җир өсте электр транспорты белән даими рәвештә пассажирлар һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында”гы Федераль законны реализацияләү хакында”гы Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү турында”гы 22-ЗРТ номерлы Законга, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына туры китереп, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2017 елның 21 ноябрендәге XXIII-3 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә гомуми файдаланудагы автомобиль транспорты тарафыннан гамәлгә ашырыла торган пассажирлар ташуны оештыру Тәртибенә (2018 елның 19 февралендәге Татарстан

Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының XXIX-3 номерлы карары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә (алга таба – Тәртип):

1.1) түбәндәге эчтәлектәге 8.1 пункты белән тулыландырырга:

“8.1.Даими ташуларның элек билгеләнгән муниципаль маршрутлары белән бергә даими ташуларның ике һәм аннан да күбрәк гомуми тукталыш пунктлары булган муниципаль маршрутларын билгеләү яки үзгәртү, әлеге маршрутларны билгеләү үзләренең компетенциясенә кергәнлектән, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы белән Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты арасында килешенеп хәл ителә”;

1.2) 28 пунктның 5 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“5)бер ел эчендә даими ташуларның муниципальара маршрутлары буенча ташуларны гамәлгә ашыруга куелган таләпләрне кабаттан Татарстан Республикасының 2015 елның 26 декабрендәге 107-ЗРТ номерлы карарының 7.1 маддәсе нигезендә билгеләнгән көйләнмәгән тарифлар буенча бозу”.

2. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча мәгълүмати-телекоммуникацион Интернет челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча мәгълүмати-телекоммуникацион Интернет челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының транспорт, төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы буенча комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советы рәисе
урынбасары И.Г.Ибраһимов